«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 15 нче кушымта

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә халык җыены нәтиҗәләре турында

04 декабрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 4 декабрендә 10 сәгать 00 минутта, 11 сәгать 30 минутта узган Татарстан Республикасы Нурлат шәһәрендә Западная, Полевая, Спартак, Нурлат шәһәрендә урнашкан гомумшәһәр су чыгару челтәрләренә тоташтыру өчен һәм кирәкле төзелеш материаллары сатып алу су бүлеп бирү челтәрләрен төзү - монтаж эшләрен башкару һәм аларга техник тоташтыру» мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарының этаплары нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Риза» - 87 кеше
«Каршы» - 0 кеше

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашкан 176 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 87 кеше, бу 50 % тәшкил итә.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 85 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 1 кеше тавыш бирде, "Тавыш бирүдән тыелдым" позициясе өчен 1 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Тимерьюлчылар» микрорайонында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Тимерьюлчылар» микрорайоны территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым акчаларын 7500 сум күләмендә кертергә.
3. Әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

«Татарстан Республикасы Нурлат шәһәрендә Западная, Полевая, Спартак, Нурлат шәһәрендә урнашкан гомумшәһәр су чыгару челтәрләренә тоташтыру өчен һәм кирәкле төзелеш материаллары сатып алу су бүлеп бирү челтәрләрен төзү - монтаж эшләрен башкару һәм аларга техник тоташтыру».

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче _______________ (имза) _________Хәмзин Р.Р._________ (имзаны расшифровкалау)